ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫЗЫЛТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

11 апрель 2019 ел №135

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлегенең муниципаль мөлкәте белән эш итү, файдалану һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында "2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Кызылтау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Кызылтау авыл җирлеге Советы карар итә:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлеге Советының 2012 елның 12 мартындагы 04 номерлы "Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлегенең муниципаль милегенә ия булу, файдалану һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлеге муниципаль милегенә ия булу, алардан файдалану һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 13.5 Пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“13.5. Муниципаль милек реестрын төзү һәм алып бару тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан каралган тәртиптә билгеләнә.”

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кызылтау авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Кызылтау авыл җирлеге башлыгы Гаффаров Ш.Р.